Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре *җаваплары*
2021-2022 нче уку елы
4 нче сыйныф

Максималь балл – 33

I. Тестны эшләгез.

1. Татар телендә генә булган тартык авазларны билгеләгез. **(1 балл)**

а) [в]

ә) [қ]

б) [ж]

в) [н]

2. Калын һәм нечкә сузыкларның парлары дөрес бирелмәгән вариантны билгеләгез. **(1 балл)**

а) [а] – [ә]

ә) [у] – [ү]

б) [ы] – [и]

в) [о] – [ө]

3. Сүзнең транскрипциясендә хата булган вариантны билгеләгез. **(1 балл)**

а) болын – [болон]

ә) колын – [колон]

б) төлке – [төлкө]

в) көлке – [көлкө]

4. Басым сүзнең соңгы иҗегенә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(1 балл)**

а) татарча

ә) китаплар

б) бакчабыз

в) сүзлектә

5. Алынма сүзләрне билгеләгез. **(1 балл)**

а) дәрес

ә) укучы

б) сүзлек

в) эшләпә

6. Омонимнарны билгеләгез. **(1 балл)**

а) карт аю – картаю

ә) төш күрдем – төш җитте

б) матур көн – чибәр кыз

в) зур өстәл – кечкенә урындык

7. Сингармонизм законына буйсынмый торган сүзне билгеләгез. **(1 балл)**

а) төлке

ә) иртә

б) салкын

в) мисал

8. Составында сүз ясагыч кушымча булган сүзне билгеләгез. **(1 балл)**

а) апага

ә) бүреләр

б) күзлек

в) урамым

9. Сүз төзелешен тикшергәндә киткән хатаны билгеләгез. **(1 балл)**

балыкчылар

а) балык – тамыр

ә) -чы – сүз ясагыч кушымча

б) -лар – сүз ясагыч кушымча

в) балыкчы – нигез

10. Су сүзенә тамырдаш булган сүзләрне билгеләгез. **(1 балл)**

а) сулык

ә) суган

б) сулы

в) сусыл

II. Теоретик бирем. (5 балл)

Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре турында языгыз. Өчәр мисал китерегез.

Сүзләр әйберләрнең төп мәгънәсен белдерсә, туры мәгънәдә (бала елмая), төп мәгънәсен белдермәсә, күчерелмә мәгънәдә (чәчәк елмая) була.

кайнар су – кайнар сәлам

авыр йөк – авыр кайгы

якты йөз – якты йолдыз

III. Гамәли-иҗади бирем. (15 балл)

1. Шигъри юлларны, төшеп калган хәрефләрен куеп, күчереп языгыз.

(3 балл: бер хәреф – 0,5 б.)

Йолд**ы**злар төш**е**п кушылган

Чыршыдагы утларга.

Кыш бабай белән Кар кызы

Килгән безн**е** котларга.

Яңа елны**ң** бә**х**етле ел

Буласын без беләбез.

Шу**ң**а күрә бергәләшеп

Яңа елга керәбез!

Роберт Миңнуллин

2. Басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз. ***(1 балл)*** *беләбез, керәбез*

3. Ел сүзенә язмача фонетик анализ ясагыз. ***(4 балл)***

Ел [йыл]

Ел: ел.

Хәрефләр: е, л.

Авазлар:

[й] – яңгырау тартык аваз,

[ы] – калын сузык аваз,

[л] – яңгырау тартык аваз.

_____

2 х., 3 ав.

4. Кыш бабайга хат языгыз. (7-10 җөмлә) ***(10 балл)***